Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы мәктәпкәчә муниципаль бюджет учреждениесе

# "Балалар бакчасында Каюм Насыйриның педагогик мирасын куллану"

**проект эше**

*__Проект авторы:__*

**“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” мөдире**

**Гыймадиева Ләйлә Мансур кызы**

**Ямаширмә , 2020**

**Эчтәлек**

Кереш …………………………………………………………………..........…. 3

Проектның актуальлеге.......................................................................................... 3

Проектның максаты һәм бурычлары.................................................................. 3 - 4

Проектның яңалыгы.............................................................................................. 5

Проектны тормышка ашыру планы ................................................................... 6 – 7

Проектының тормышка ашыру этаплары ........................................................... 7

Көтелгән нәтиҗәләр.................................................................................................8

Проектны тормышка ашыуны тәэмин итү өчен кирәкле шартлар......................... 8

**Кереш.**

Халкыбызның борынгы гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнү —балаларның милли рухта тәрбияләүнең мөһим бер юнәлеше.

Гореф-гадәтләр, йолалар халык тормышының, мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Алар зәгыйфьләнә икән — халыкның мәдәнияте, яшәеше дә гарипләнә.

Халык бәйрәмнәре, аларга караган күп кенә гореф-гадәт, йолалар шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләренә күнектерү чарасы да булып хезмәт итә. Бу чараларда халыкның олысы-кечесе теләп катнаша, һәр буын кешесе анда катнашу тәртибен гадәт, традиция рәвешендә үзенә сеңдерә. Кеше кайда гына яшәсә дә, бу традицияләр аны туган нигезенә тартып тора.

Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр берни белән дә алыштыргысыз тәрбия чарасы булып тора. Һәр кеше, үзе дә сизмәстән, үзара аралашу, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, тәрбияләнә. Милли бәйрәмнәр, йолалар кимү үзара аралашу, очрашу-күрешүләрнең сирәгәюенә китерәчәк.

Халкыбыз: «Үгет-нәсыйхәт – бездән, әдәп белү үзеңнән», – дип, бик дөрес әйткән. Иң асыл рухи-әхлакый кыйммәтләр, дөрес яшәү кануннары  һәм татар халкының тәрбия тәҗрибәсендә тупланган. Әнә шул изге мирасны – бәһасез кыйммәтләрне – үзләштереп, яшь кеше үзенең рухи тормышын, әдәп-әхлагын, чынбарлыкка карашын һәм гамәлләрен уңай якка үзгәртсә, үзенең яшәү рәвеше, тормыш, итү кагыйдәләре итеп кабул итә алса, андый инсан киләчәктә үзенә дә, гаиләсенә дә, әйләнә-тирәдәгеләргә дә иманлы, бәрәкәтле яшәү үрнәкләре күрсәтә алачак. Ләкин бу  гаять катлаулы проблеманы хәл итү белән бәйле процесс.

Туган илгә һәм туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, әдәп-әхлакка өйрәтү, иман нуры тарату, адәм баласын кеше итү бигрәк тә читен, чөнки яшьләрнең бик күбесенең бүгенге кыенлыклардан зиһене тарала, алар дөньяда яшәү мәгъәсенә төшенми башлый. Нәкъ менә шул максатларны күздә тотып әлеге проектны төзү

зарурлыгы туды. Халкыбызның милли мирасын югалтмау, аны кадерләп саклап тоту безнең изге бурычыбыз.

## 1. Проектның актуальлеге

Үткәне юкның – киләчәге юк, ди халык. Бу гыйбарәләр буш урында тумаган. Ул – үткәнгә хәер хаклы һәм сак мөнәсәбәт, үткән буынга олы рәхмәт хисе хакында сөйли, үткәнен белгән, узган сәхифәләргә хөрмәт белән караган, аларны кадерләгән халыкның гына киләчәге барлыгы хакында кисәтә.Милли мирас билгеле бер халыкның җәмгыять үсеше барышында туплаган бай тәҗрибәсен, гореф-гадәтләрен, әхлагын үз эченә ала. Милли мәдәниятнең гуманитар юнәлеше аның эчтәлегендә күренә. Проектның бурычы – Каюм Насыйриның педагогик мирасын куллану аша әнә шул элементларны балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә җиткерү.

## 2. Проектның максаты һәм бурычлары

**Проектның максаты:**

- икетелле белем бирү шартларында балалар бакчасында Каюм Насыйриның педагогик мирасына таянып балаларга милли тәрбия бирү, әхлакый кыйммәтләрне үстерү;

**Проектның бурычлары:**

- татар халкының милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен саклау, аларны җыю, туплау, өйрәнү, киләчәк буыннарга тапшыруны Каюм Насыйриның мирасы нигезендә оештыру;

- тәрбияләнүче һәм тәрбиячеләрнең милли мирасны саклау буенча актив тормыш позицияләрен формалаштыру;

- халыкның милли мирасын саклау юлы аша балаларда үз халкыңның үткәне һәм киләчәге өчен җаваплылык хисе булдыру;

- мәктәп һәм балалар бакчасы музее эшчәнлеге аша үз халкың, туган ягың, балалар бакчасы һәм мәктәбең өчен горурлык хисе тәрбияләү;

- әти-әниләр белән эшчәнлектә Каюм Насыйри мирасларын, нәсыйхәтләрен файдалану.

- укыту-тәрбия процессында “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасында милли мәдәниятне өйрәнү, милли мирасны саклау өчен нигез булдыру;

3. **Проектның яңалыгы:**

   Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр, әти-әниләр белән берлектә социаль яктан файдалы проект эшчәнлеген булдыру, балалар бакчасында социаль яктан файдалы проект эшчәнлегенең инновацион тәҗрибәләрен булдыру.

**4. Проект эшчәнлеге түбәндәге мөмкинчелекләрне ача:**

* җәмгыть һәм халкыбыз өчен файдалы эшчәнлеккә тәрбияләнүчеләрне җәлеп итү;

* тәрбияләнүчеләрнең, әти-әниләрнең шәхси тәҗрибәсе белән балалар бакчасы тормышын уңышлы бәйләү;

* бүгенге җәмгыть шартларында шәхестә иң кирәкле булган сыйфатлар инициативалык, җаваплылык, мөстәкыйльлек кебек сыйфатлар формалаштыру;

* халыкның милли мирасын саклау, аны дәвам итүнең нигезләрен булдыру;

* тәрбияләнүчеләр һәм педагогларның лидерлык сыйфатларын ачарга ярдәм итү.

## 4. Проектны тормышка ашыру планы:

| № | Тема, эшчәнлек төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| **1. Балалар тәрбияләүдә Каюм Насыйри фикерләрен кулланунның заманча алымнары** | | | |
| 1 | Күчмә папка кую "Каюм Насыйри тормыш һәм иҗат юлы" | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр |
| 2 | "Кунак каршылау" (ачык белем бирү эшчәнлеге) | Октябрь | Мифтахова А.А. |
| 3 | "Дару үләннәре" темасына карата ЛЭПБУК ики китап ясау. | Ноябрь | Асылгәрәева А.А. |
| 4 | "Безнең тирәдә үсә торган дару үләннәре" темасына рәсем конкурсы | Декабрь | Яруллина А.Р. |
| 5 | "Дару үләннәр"  темасына күчмә папка кую | Ел дәвамында | Асылгәрәева А.А. |
| 6 | Мастер-класс «Шифалы үләннәр» (балалар белән гербарий ясау). | Гыйнвар | Мифтахова А.А. |
| 7 | "Татар халык бизәкләре" темасына мастер класс үткәрү(зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме) | Февраль | Асылгәрәева А.А. |
| 8 | "Безнең нәсел агачы" бәйгесе | Март | Мифтахова А.А. |
| 9 | "Әкиятләр иленә сәяхәт" (ачык белем бирү эшчәнлеге) | Апрель | Гыйләҗиева Э.Р. |
| 10 | "Өстәл янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре" ( ачык белем бирү эшчәнлеге) | Май | Яруллина А.Р. |
| **2. Мәктәпкәчә  яшьтәге балаларны тәрбияләү турында Каюм Насыйри нәсыйхәтләре (әти-әниләр өчен)** | | | |
| 1 | «Балаларга әхлак тәрбиясе бирүдә Каюм Насыйри мирасын кулллану"әти-әниләр җыелышында чыгыш | Сентябрь | Мифтахова А.А. |
| 2 | "Халык фольклоры – кече яшьтәге балаларның балалар бакчасына нәтиҗәле ияләштерү юлы" | Октябрь | Асылгәрәева А.А. |
| 3 | "Акыллы балаларга – акыллы китаплар" | Декабрь | Хадиева Г.И. |
| 4 | "Халык уеннары аша бала тәрбияләдә әти-әнинең роле" | Март | Гыйләҗиева Э.Р. |
| 5 | "Әдәпле булу авырмы?" ("Китаб – әт-тәрбия"(уналтынчы тәрбия) | Март | Яруллина А.Р. |
| 6 | "Уеннар аша бала тәрбияләнең | Март | Мифтахова А.А. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әһәмияте. Балачак уеннары” | | |
| **3. Каюм Насыйриның методик принципларына нигезләнеп сөйләм телен үстерү** | | | |
| 1 | “К. Насыйри хикәятләре белән таныштыру” | План буенча | Мифтахова А.А. Хадиева Г.И. |
| 2 | Икенче кече яшьтәгеләр төркеме балалары белән ел дәвамында әкиятләр уку, бармак уеннары, әйтемнәр өйрәнү, татар халкының җырлы- биюле уеннарын өйрәнү: “Әйт әле үскәнем”, “Матур түгәрәк”, “Ак калач” , “Куянкай” һ.б. | План буенча | Асылгәрәева А.А. Сәмигуллина Г.Н. |
| 3 | Каюм Насыйриның “Эт һәм сөяк”, “Ана һәм бала”, “Челән белән чыпчык” әкиятләрен уку | План буенча | Гыйләҗиева Э.Р. Хадиева Г.И. |
| 4 | “Мәкальләр һәм әйтемнәр нигезендә балаларга әхлакый тәрбия бирү” | План буенча | Яруллина А.Р. Сәмигуллиан Г.Н. |
| 5 | К.Насыйри мәсәлләре аша балаларга тәрбия бирү | План буенча | |

## 5. Проектны тормышка ашыру этаплары

Проект 2,5 дәвамында эшләнүгә исәпләнелгән.

I этап: 2020 нче елның беренче яртысы – эзләнү эше алып бару, анализ, проблемаларны ачыклау, максат кую, бурычлар, проектны тормышка ашыру планын төзү

II этап: 2020 - 2021 еллар – практик: проектны тормышка ашыру

III этап: 2021-2022 еллар – анализлау. Нәтиҗәләр чыгару.

Тәрбияләнүчеләр белән еллар дәвамында тупланган материаллар, өйрәнгән җырлары, уеннары, милли киемнәрнең үзенчәлекләре, шулай ук танылган якташлар белән очрашу оештыру- болар барысы да проектны тормышка ашыруда ярдәм итә. Әлбәттә, монда тәрбияләнүчеләр һәм тәрбиячеләрнең генә түгел, ә гаиләнең дә роле бик зур, шунлыктан гаиләдә милли тәрбия бирүгә зур игътибар бирү кирәк.

**6. Көтелгән нәтиҗәләр:**

- тәрбияләнүчеләрнең иҗади активлыкларына ирешү;
- тәрбиячеләрнең педагогик осталыкларын үстерү;
- тәрбияләнүчеләрнең социаль активлыгы арту, милли мирасны өйрәнүгә теләк барлыкка килү, аны буыннан-буынга дәвам итүне булдыру;
- гаиләдә,мәктәптә милли гореф-гадәтләрне үтәү һәм башка милләтләрнең мирасына да хөрмәт белән карау;

**7. Проектны тормышка ашыуны тәэмин итү өчен кирәкле шартлар:**

* балалар бакчасының материаль-техник базасын  ныгыту;
*тәрбияләнүчеләр , әти-әниләр, мәктәп белән дәвамчанлыкны ныгыту;
* педагог әлеге эшчәнлек шартларында әйдәп баручы ролен үтәргә тиеш.

Милли тәрбия, аның әһәмияте, алга таба аны саклауның кирәклеген төшендерү бик әһәмиятле. Педагог эшчәнлек барышында үзенең максатларын, эшчәнлегенең төп юнәлешләрен күзаллау, перспективаларны күрә белү, аны тормышка ашыруның юлларын таба белү, проектларны планлаштыра белү , социаль эзләнүләр күнекмәләре үзендә булдыру, яңа технологияләрне белү, актив интерактив методларны куллана белү әһәмияткә ия.

Кушымта № 1

**Проектның төп чаралары. Проектны тормышка ашыруның юл картасы**

| № | Чаралар | Үтәү срогы | Җаваплы | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| **1. Оештыру чаралары** | | | | |
| 1 | Проектны тормышка ашыручы эш төркеме булдыру | Гыйнвар, 2020 | Мөдир Тәрбиячеләр | Проектны тормышка ашыруда эш группасын раслау |
| 2 | Проектны тормышка ашыруның план-графигын эшләү | Февраль-март, 2020 | Мөдир Тәрбиячеләр | Проектны тормышка ашыруның план-графигын эшләү һәм раслау |
| 3 | Проект чараларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү оешмасының локаль актларын эшләү | Апрель, 2020 | Мөдир | Проект чараларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү оешмасының локаль актларын эшләү, карау һәм раслау |
| **2. Төп чаралар** | | | | |
| 1 | “Каюм Насыйри нәсыйхәтләренә таянып эш алып барабыз”. Түгәрәк өстәл | Сентябрь, 2021 | Мөдир | Җәмәгатьчелек игътибарын Каюм Насыйри нәсыйхәтләренәтаянып тәрбия бирүгә юнәлтү. Иҗтимагый партнерлар, ата-аналар һәм педагогик җәмәгатьчелек түгәрәк өстәле эшендә катнашу |
| 2 | Төркемнәрдә Каюм Насыйри педагогикасына нигезләнгән белем бирү эшчәнлекләре уздыру | Октябрь, 2021 | Тәрбиячеләр | Төркемнәрдә Каюм Насыйри педагогикасына нигезләнгән белем бирү эшчәнлекләрен карау |
| 3 | Үстерелешле этномәдәни мохит булдыру | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | Мәктәпкәчә белем бирү учрежденияләре, тәрбияләнүчеләр өчен фәнни-үсеш ала торган этномәдәни мохит булдыру |
| 4 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны | Ел дәвамында | Мөдир Тәрбиячеләр | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тәрбияләү турында Каюм Насыйри нәсыйхәтләре (әти-әниләр өчен) түгәрәк өстәлләр, күчмә папкалар туплау | | | турында Каюм Насыйри нәсыйхәтләрен куллану гаиләдә бала тәрбияләү өчен төп чара |
| 5 | “Туган тел” атналыгы үткәрү | Февраль, 2021 | | «Туган тел” атналыгы проекты кысаларында татар халкының мәдәнияте торышын тикшерү, аны саклау һәм торгызу буенча төп эш юнәлешләрен билгеләү, социаль партнерлар белән тәҗрибә уртаклашу буенча семинарлар, концерт-массакүләм чаралар, конференцияләр үткәрү планлаштырыла. Халык иҗаты түгәрәкләре, түгәрәк өстәлләр, семинарлар, мастер-класслар һәм башка мәдәни акцияләр оештырылачак, иҗади кешеләргә, тәрбияләнүчеләргә ярдәм күрсәтеләчәк. Татар халык мәдәниятен саклап калуга юнәлдерелгән чаралар уздырылачак, халык мәдәнияте гореф-гадәтләрен заманча мәдәни практикага һәм иҗтимагый тормышка кертү ысуллары һәм формалары эшләнәчәк. Тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр һәм ата- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | аналар җәмәгатьчелегенең фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, конкурсларда катнашуы, фольклор кичәләр үткәрү, татар халкының мәдәниятен һәм телен үстерү белән бәйле чаралар оештыру һәм әзерләү планлаштырыла. |
| 6 | Каюм Насыйриның методик принципларына нигезләнеп сөйләм телен үстерү буенча тәрбияләнүчеләр белән эшчәнлек | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр Мөдир | Каюм Насыйриның методик принципларына нигезләнеп сөйләм телен үстерү буенча тәрбияләнүчеләр белән эшчәнлек. Каюм Насыйриның хикәятләре, мәкаль һәм әйтемнәре, мәсәлләре белән танышу аша балаларның сөйләм телен үстерү. |
| 7 | Татар фольклоры материаллары ярдәмендә рухи-әхлакый тәрбия бирүгә юнәлдерелгән яңа ел чаралары | Декабрь | Мөдир Тәрбиячеләр | Тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр һәм ата-аналар җәмәгатьчелегенең Яңа елны бәйрәм итүгә багышланган чараларда катнашуы, мәктәпне фольклор бизәү, фольклор кичәләре уздыру. |
| **3. Проектны мәгълүмати яктан тәэмин итү буенча чаралар** | | | | |
| 10 | Белем бирү оешмасының сайтында проект чараларын этаплап урнаштыру | Ел дәвамында | | Сайтның бүлеген булдыру, проект чараларын этаплап мәгариф оешмасының дәрестән тыш эшчәнлек сайтында урнаштыру (план-график, үткәрелә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | торган чаралар турында мәгълүмат, фотоотчетлар) |
| 11 | Әти –әниләр өчен түгәрәк өстәл һәм конференция үткәрү өчен буклетлар чыгару | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | Каюм Насыйри нәсыйхәләре буенча "түгәрәк өстәл" дә катнашучылар һәм кунаклар өчен буклетлар чыгару |
| 12 | Мәгълүмати стенд булдыру | Ел дәвамында | Тәрбиячеләр | Тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр, ата-аналар җәмәгатьчелеге өчен мәгълүмат стенды булдыру һәм эшләү |
| 13 | Проектны Интернет-тәкъдим итү | 2022 нче ел | | Бакчаның Сайтында проектны Интернет-тәкъдим итү |